**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**24 ноябрь 2023 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (мең сум) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
- Су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;
- Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау;
- Авыл эчендәге юлларны сезонлы карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: В.П. Вафина

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы: В.П. Вафина